КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 27 декабрь г.Казань № 1694

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы мәдәниятен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 16 декабрь, 997 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасы мәдәниятен үстерү» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы мәдәниятен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 16 декабрь, 997 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 25 август, 610 нчы; 2015 ел, 5 ноябрь, 837 нче; 2015 ел, 5 декабрь, 921 нче; 2016 ел, 22 сентябрь, 673 нче; 2017 ел, 21 февраль, 104 нче; 2017 ел, 24 июнь, 426 нчы; 2017 ел, 26 июнь, 431 нче; 2017 ел, 6 октябрь, 767 нче; 2017 ел, 27 декабрь, 1051 нче; 2018 ел, 3 октябрь, 899 нчы; 2018 ел, 29 декабрь, 1325 нче; 2019 ел, 6 июнь, 473 нче; 2019 ел, 5 ноябрь, 1011 нче; 2020 ел, 29 август, 758 нче; 2021 ел, 8 декабрь, 1201 нче; 2022 ел, 30 май, 501 нче; 2022 ел, 31 август, 930 нчы; 2022 ел, 30 декабрь, 1478 нче, 2023 ел, 29 август, 1037 нче, 2023 ел, 4 октябрь, 1224 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Татарстан Республикасы мәдәниятен үстерү» дәүләт программасына (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«2014 - 2025 елларга музей эшен үстерү» ярдәмче программасына кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә);

«2014 - 2025 елларга театр сәнгатен үстерү» ярдәмче программасына кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә);

«2014 - 2025 елларга китапханә эшен үстерү» ярдәмче программасына кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә);

«2014 - 2025 елларга кинематографияне саклау һәм үстерү» ярдәмче программасына кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә);

«2014 – 2025 елларга мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә белем бирүне үстерү» ярдәмче программасына кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә);

consultantplus://offline/ref=FEF48A1FAC9C23F7F72A5118F1C3FA3BEA4F2D9BD70E085E337B170ED565AC0BA1813240F3E69DD93C42F22EAE1854CA26BBDDF1072646C7DBDC5044G9b5L«Халык иҗатына ярдәм итү. 2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы җирле халыкларының матди булмаган мәдәни мирасын саклап калу, торгызу һәм популярлаштыру» ярдәмче программасы максаты, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм чараларын финанслау" ярдәмче программасына кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә);

«2014 – 2025 елларга мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни ядкарьләрне) саклап калу, алардан файдалану, аларны популярлаштыру һәм аларга дәүләт саклавы» ярдәмче программасына кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә);

«2014 – 2025 елларга төбәкара һәм милләтара мәдәни хезмәттәшлекне үстерү» ярдәмче программасына кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә);

«2014 - 2025 елларга заманча сәнгатьне үстерү» ярдәмче программасына кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә);

«2014 - 2025 елларга тармакның кадрлар потенциалын үстерү» ярдәмче программасына кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә);

«2014 - 2025 елларга тармакның дәүләт идарәсен үстерү» ярдәмче программасына кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә);

«Татарстан Республикасы мәдәниятен үстерү» дәүләт программасы кысаларында социаль һәм инженерлык инфраструктурасын үстерү» ярдәмче программасына 1 нче кушымтада:

«Дәүләт (муниципаль) милке объектларына капитал салулар*» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «Дәүләт (муниципаль) милке объектларына капитал салулар* | ТР ММ, ТР ТАһТКХМ, ТР БИТИ ДКУ, «ИВФ» ККО, ТР ИМ, ҖҮО (килешү буенча) | 2020 – 2024 еллар | Мәдәният оешмаларының төзелгән (реконструкцияләнгән) һәм капиталь ремонтланган объектлары саны, барлыгы, берәмлек | - | - | - | - | 150 | 156 | 160 | 171 | 182 | 190 | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - | -»; |

«*» астөшермәсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

*«Мәдәни мохит» төбәк проекты кысаларында чара (2021 елда 4 мәдәни-ял итү учреждениесе, 1 театр; 2022 елда 8 мәдәни-ял итү учреждениесе, 1 музей, 1 балалар сәнгать мәктәбе; 2023 елда 5 мәдәни-ял итү учреждениесе, 2 музей, 3 балалар сәнгать мәктәбе, 1 театр; 2024 елда 5 мәдәни-ял итү учреждениесе, 2 музей, 1 театр төзү, эшләү (реконструкцияләү) һәм капиталь ремонтлар каралган).».

2. Бу карар 2023 елның 31 декабренә кадәр (31 декабрьне кертеп) гамәлдә була дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин